ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 апрель 2024ел № 2213

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны алмашу һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибе турында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю тәртибе турында, аны алмашу һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибе турында» 2011 елның 29 июнендәге 530 номерлы карары, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү системасын камилләштерү, кешеләр гомерен һәм сәламәтлеген саклауны тәэмин итү, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә әйләнә-тирә табигать мохитенә китерелгән зыян һәм материаль югалтулар күләмен киметү максатында

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны алмашу һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибен (алга таба - Тәртип) кушымтада каралганча расларга.

2. Оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, шәһәр оешмалары җитәкчеләренә Тәртип, килешүләр нигезендә яки запрос буенча үз вакытында Яр Чаллы шәһәренең Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат тапшыруны тәкъдим итәргә.

3. Гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы һәм фактлары турында мәгълүмат тапшыру, шул исәптән дәүләт, ведомство һәм башка элемтә чараларыннан файдаланып, түләүсез нигездә беренче чиратта гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан

Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 5 апрелендәге
2213 номерлы карарына
кушымта

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне
гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю,
аны алмашу һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан
хакимият органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү
тәртибе

1. Әлеге тәртип мәгълүмат җыю, аны алмашу, һәлакәт яки гадәттән тыш хәл барлыкка килгәндә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтләнгән дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм, оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, оешмаларга хәбәр итү һәм үзара эшчәнлек механизмын билгели.

2. Яр Чаллы шәһәрендә гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыюны һәм көндәлек эшчәнлектә аны алмашуны түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

- шәһәр дәрәҗәсендә - МБУ «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ исеменнән Яр Чаллы шәһәренең Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте (алга таба - Яр Чаллы шәһәренең БДДХ);

- объект дәрәҗәсендә - оешмаларның (объектларның) дежур-диспетчерлык хезмәтләре.

3. Һәлакәтләр һәм гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, Яр Чаллы шәһәре территориясендәге дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибе әлеге тәртипкә 1 нче кушымтада күрсәтелгән.

4. Мәгълүмат җыюны, аны алмашуны, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча мәсьәләләрне хәл итү аларның вәкаләтләренә кергән дәүләт хакимияте органнарының һәм оешмаларының үзара эшчәнлеген һәм аларга хәбәр итүне оештыруның төп максатлары булып тора:

- гадәттән тыш хәлләр куркынычы һәм кешеләр тормышын, сәламәтлеген саклауга һәм матди кыйммәтләрне саклауга юнәлдерелгән кичектергесез гамәлләр турында үз вакытында хәбәр итү, шул исәптән халыкка;

- аның нәтиҗәләрен бетерү өчен кирәкле көчләрне һәм чараларны исәпләү, коткару һәм башка кичектергесез эшләрне, сәнәгать аварияләрен, катастрофаларны һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү буенча, шулай ук һәлакәтләрнең, гадәттән тыш хәлләрнең нәтиҗәләрен бетергәннән соң, аларның йогынтысын киметү буенча чаралар оештыру һәм үткәрү турында карар кабул итү өчен, бәла-казалар масштаблары турында тулы һәм дөрес мәгълүмат белән тәэмин итү;

- гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча чараларны оештыру өчен, шулай ук Яр Чаллы шәһәренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының шәһәр звеносын (алга таба - ГТХТС) алга таба үстерү һәм камилләштерү буенча карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар белән тәэмин итү.

5. Һәлакәтләр һәм гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- табигый һәм техноген характердагы һәлакәтләр һәм гадәттән тыш хәлләр фаразы, аларның барлыкка килү фактлары һәм нәтиҗәләре турында;

- һәлакәтләр һәм гадәттән тыш хәлләр зоналарындагы хәлләр, аларны локальләштерү һәм бетерү буенча эшләрнең барышы һәм нәтиҗәләре турында, аларның кайсы ведомствога

каравын, шулай ук аларның җитәкчесенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын һәм элемтә телефонын күрсәтеп, аларны бетерү өчен җәлеп ителгән көчләрнең һәм чараларның составы турында (үзара эшчәнлекне һәм идарәне оештыру өчен);

- гадәттән тыш хәлләрне һәм һәлакәтләрне кисәтү буенча планлаштырыла торган чаралар турында, аларның кайсы ведомствога каравын, аларның җитәкчесенең фамилиясен, исемен, атасының исемен, вазыйфасын һәм элемтә телефонын күрсәтеп, аларны бетерү өчен җәлеп итү өчен планлаштырыла торган көчләрнең һәм чараларның составын исәпләү турында;

- потенциаль куркыныч объектларның һәм территорияләрнең торышы турында;

- гадәттән тыш хәлләр зоналарында ГТХТС көчләренең һәм коткару чараларын һәм кичектергесез эшләрне башкаруга җәлеп ителә торган башка көчләрнең булуы, комплектлылыгы, җиһазланышы һәм гамәлләре турында;

- гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләрен тәэмин итү өчен кирәкле финанс, азык-төлек, медицина һәм матди-техник ресурсларның гадәттән тыш резерв фондлары булу, аларның торышы һәм алардан файдалану турында.

Мәгълүмат приказлар, боерыклар, белдерүләр, хәбәрләр, докладлар, сводкалар, хәлләрне тасвирлаган карталар, хәбәр итү сигналлары рәвешендә һәм башка формада тапшырылырга мөмкин.

6. Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларының нәтиҗәлелегә аларның барлыкка килү фактлары һәм фаразы турындагы мәгълүматның үз вакытында булуына, дөреслегенә һәм тулылыгына бәйле.

7. Хәбәрләрне тапшыру тәртибе һәм ешлыгы, әлеге тәртипкә 1 нче кушымтада каралганча, гражданнар оборонасы, Яр Чаллы шәһәре халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге мәгълүмат докладлары регламенты белән билгеләнә.

Мәгълүматны тапшыру тәртибе, составы һәм формасы тиешле ике яклы яки күпьяклы килешүләр белән билгеләнә.

8. Эчтәлегенә бәйле рәвештә, мәгълүмат оператив һәм планлы булырга мөмкин.

Оператив мәгълүматка табигый, техноген, биологик-социаль характердагы фаразлана торган һәм (яки) балыкка килгән гадәттән тыш хәлләр һәм аларның нәтиҗәләре турында мәгълүматлар, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен җәлеп ителә торган даими әзерлектәге ГТХЧС чаралары һәм көчләре турында мәгълүматлар, шулай ук аларның гадәттән тыш хәлләрне кисәтүгә һәм бетерүгә юнәлдерелгән эшчәнлеге турында мәгълүматлар керә.

Планлы мәгълүматка административ-территориаль берәмлекләр турында, оешмалар һәм аларның гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чараларны алдан планлаштыру өчен кирәкле эшчәнлеге турындагы мәгълүматлар керә. Планлы мәгълүматка мәҗбүри тәртиптә административ-территориаль берәмлекләрнең халык саны һәм оешмалар хезмәткәрләре турында мәгълүматлар кертелә.

9. Гражданнар оборонасы буенча һәм гадәттән тыш хәлләр турында мәгълүматның төп чыганаклары булып, Яр Чаллы шәһәренең БДДХ, икътисад объектлары җитәкчеләре һәм ведомство карамагындагы территорияләрдә һәм объектларда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр һәм һәлакәтләр турында барлык мәгълүматны кичекмәстән Яр Чаллы шәһәренең БДДХга һәм Башкарма комитетның гражданнар оборонасы һәм халыкны саклау бүлекчәсенә җиткерергә тиешле дежур-диспетчерлык хезмәтләре тора.

Хәлне тулысынча ачыклаганчы, гадәттән тыш хәл куркынычы һәм факты турында ашыгыч мәгълүмат тапшыруны тоткарлау рөхсәт ителми.

Мәгълүмат чыганагы тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплы.

10. Гадәттән тыш хәл барлыкка килү куркынычы һәм факты турында мәгълүмат Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат тапшыру сроклары һәм формалары турында инструкцияләрне раслау хакында» 2021 елның

11 гыйнварындагы 2 номерлы приказы белән билгеләнгән тәртиптә һәм формаларда тапшырыла.

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге мәгълүмат, әлеге Тәртипкә 3 нче кушымтада каралганча, Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнары һәм оешмалары тарафыннан тапшырыла.

Җыелган һәм эшкәртелгән мәгълүмат нигезендә, республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар үз эшчәнлеге өлкәсендә гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат базаларын формалаштыралар, аларны актуальләштерүне гамәлгә ашыралар һәм мәгълүмат базалары структурасы һәм аларның форматы турында мәгълүматны ТР буенча Россия ГТХМ ДУ мәгълүмат базасына тапшыралар.

11. ГТХТСның көндәлек идарә органнарының оператив-дежур хезмәтләренә, үз компетенциясе чикләрендә, үзара эшчәнлек алып баручы идарә органнарыннан мәгълүмат сорау һәм алу хокукы бирелә.

12. Яр Чаллы шәһәре территориясендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне рәсми исәпкә алуны һәм алар турында хисапны Яр Чаллы шәһәренең БДДХ алып бара.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы — Л.Р. Абдуллина

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны алмашу һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан хакимият органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибенә 1 нче кушымта

Гадәттән тыш хәлләр һәм һәлакәтләр барлыкка килгәндә, Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан хакимият органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибе

| № т/б | Ведомствоның, оешманың исеме | Оператив дежурларның, диспетчерларның телефоннары | Гадәттән тыш хәлләр һәм һәлакәтләр | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Автотранспорттагы һәлакәтләр ( эре юл-транспорт һәлакәтләре) | Федераль трассалардагы һәлакәтләр (ГТХ) | Тимер юл транспортындагы һәлакәтләр (ГТХ) | Су транспортындагы һәлакәтләр (ГТХ) | Авиатранспорттагы һәлакәтләр (ГТХ) | Урман янгыннары | Куркыныч йөк тәялгән транспорттагы һәлакәтләр (ГТХ) | Газүткәргечләрдәге һәлакәтләр (ГТХ) | Нефть үткәргечләрендәге һәлакәтләр (ГТХ) | Авария химик куркыныч матдәләр таралудан һәлакәтләр (ГТХ) | Биологик куркыныч характердагы һәлакәтләр (ГТХ) | Энергия системаларындагы һәлакәтләр (ГТХ) | ТКХ объектларындагы һәлакәтләр (ГТХ) | Куркыныч геологик күренешләр | Радиоактив элементлы һәлакәтләр (ГТХ) | Авыл хуҗалыгы объектларындагы һәлакәтләр (ГТХ) | Гидротехник корылмалардагы һәлакәтләр (ГТХ) | Рудникларда, шахталардагы, мәгарәләрдәге һ.б. һәлакәтләр (ГТХ) | Социаль әһәмияткә ия объектлардагы һәлакәтләр (ГТХ) | Потенциаль куркыныч объектлардагы, янгын-шартлау куркынычы булган объектлардагы һәлакәтләр (ГТХ) | Гидрометеорологик һәм башка күренешләр | Эпидемиологик характердагы һәлакәтләр (ГТХ) | Экологик характердагы һәлакәтләр (ГТХ) | Социаль-икътисадый характердагы һәлакәтләр (ГТХ) |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 | 23 | 24 | 25 | 26 | 27 |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты | 30-55-42, 30-59-31 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 2. | Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Баш идарәсенең Дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 нче янгын сүндерү-коткару отряды | 23-73-01 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 3. | «Татарстан Республикасы буенча дәүләт янгынга каршы хезмәте федераль янгынга каршы хезмәтенең килешү бүлекчәләре идарәсе» ФДБУның Яр Чаллы филиалы - Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең федераль янгынга каршы хезмәте отряды | 21-94-04 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4. | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча ТР ГТХМ идарәсе | 54-67-32 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 5. | «Янгын сүндерү-коткару отряды» МБУ | 23-03-00 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 6. | Яр Чаллы шәһәренең 6 нчы зона эзләү-коткару отряды | 49-11-01 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 7. | Россия Тимер юл транспорты ведомство сагы ФДП Волжск филиалының Уфа ведомство сак отряды | 99-05-71 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 8. | «Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Россия милли гвардия гаскәрләренең ведомстводан тыш сак идарәсе» ФДКУ филиалы - Яр Чаллы шәһәре буенча ведомстводан тыш сак бүлеге | 52-87-85, 52-21-11, 52-30-80 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Росгвардиянең «Сак» ФДУП Сәнәгать объектларын саклау үзәге Идел буе Федераль округы буенча идарәсенең «Сак» ФДУП (филиал) | 37-25-08, 37-22-26 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 10. | ТР буенча Росгвардия «Сак» ФДУП филиалының үзәкләштерелгән сак пульты | 51-78-68 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 11. | Росгвардия «Сак» ФДУП Яр Чаллы шәһәре буенча бүлеге | 70-94-50, 70-94-54 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 12. | ТР буенча Россия ГТХМ ДУ Кече суднолар буенча дәүләт инспекциясе үзәгенең Яр Чаллы инспекторлык бүлеге | 49-31-06 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 13. | Яр Чаллы шәһәре буенча Россия ЭЭМ идарәсе | 02, 37-90-00, 37-90-10 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 14. | «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССУ | 30-48-00 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 15. | «Чаллыгаз» файдалану-җитештерү идарәсе | 71-73-33,<br>71-75-59,<br>71-72-58 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 16. | «ВолгоПромГаз» ҖЧҖ | 40-05-95 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 17. | Татарстан Республикасы буенча Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәте идарәсенең Яр Чаллы шәһәрендәге, Актаныш, Тукай, Минзәлә районнарындагы территориаль бүлеге | 32-06-07,<br>34-98-90,<br>32-05-90 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 18. | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе | 59-36-39 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 19. | «Челтәрләр компаниясе» АҖ филиалы - Яр Чаллы электр челтәрләре | 74-55-52, 39-58-53 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 20. | «Татэнерго» АҖ филиалы - «Яр Чаллы җылылык челтәрләре» | 33-71-03, 33-71-05, 33-70-29 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 21. | «Чаллы су каналы» ҖЧҖ | 53-44-50, 39-70-73 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 22. | «Автомобиль юллары предприятиесе» МУП | 20-36-36 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 23. | «Жилкомсервис» ҖКФ» ҖЧҖ | 70-33-89, 70-33-89 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 24. | «Челнистройремонт» ИО» ҖЧҖ | 54-19-22, 56-42-11 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 25. | «Мәхәллә» ИК ҖЧҖ | 34-59-23 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 26. | «Электротехник» ИК ҖЧҖ | 25-33-07, 25-33-08 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 27. | «Камстройсервис» ИК ҖЧҖ | 54-44-22, 56-31-93 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 28. | «Ремжилстрой» ИК ҖЧҖ | 91-77-20 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 29. | «Яр Чаллы шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ | 46-91-41, 46-47-34, 46-96-71 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 30. | «Шәһәр хуҗалыгы дирекциясе» МАУ | 71-47-89 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |
| 31. | «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» ФБССУ Яр Чаллы филиалы | 46-64-54 | + | + | + | + | | + | + | + | + | + | | + | + | | | | + | | + | + | + | + | + | + |

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны алмашу һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан хакимият органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибенә 2 нче кушымта

Гражданнар оборонасы, Яр Чаллы шәһәре халыкын һәм территориясен гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат докладлары регламенты

| № т/б | Мәгълүматның эчтәлеге | Кем тапшыра | Кая (кемгә) тапшыра | Мәгълүмат тапшыру срогы һәм ешлыгы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Яр Чаллы шәһәре территориясендә урын алган гадәттән тыш хәлләрне анализлаган хисап | Яр Чаллы шәһәренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссия рәисе | Яр Чаллы шәһәре БДДХга | узган ай өчен - ай саен беренче числога |
| 2. | Ведомство буйсынуындагы объектларда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләргә анализ | потенциаль куркыныч объектлары булган министрлыклар, ведомстволар һәм оешмалар - техноген гадәттән тыш хәлләр буенча | 1. Татарстан Республикасының тиешле министрлыкларына, ведомстволарына һәм оешмаларына.<br>2. Яр Чаллы шәһәре БДДХга.<br>3. Яр Чаллы шәһәренең гадәттән | узган ел өчен - ел саен 10 гыйнварга<br>узган ел өчен - ел саен 1 гыйнварга |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясенә.<br>4. Татарстан Республикасы ГТХМга | |
| 3. | Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча планлаштырыла торган чаралар турында | потенциаль куркыныч объектлары булган министрлыклар, ведомстволар һәм оешмалар - техноген гадәттән тыш хәлләр буенча | 1. Татарстан Республикасының тиешле министрлыкларына, ведомстволарына һәм оешмаларына.<br>2. Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Кризислы хәлләрдә идарә итү үзәгенә | киләсе ел өчен - ел саен 1 декабрьгә |
| | | Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнары - табигый, эпидемиологик һәм социаль-икътисадый гадәттән тыш хәлләрдә | 1. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча комиссиясенә<br>2. Татарстан Республикасы буенча Россия ГТХМ Кризислы хәлләрдә идарә итү үзәгенә.<br>3. Татарстан Республикасы ГТХМга. | киләсе ел өчен - ел саен 15 декабрьгә |
| 4. | РСЧС функциональ ярдәмче системаларның, РСЧС территориаль ярдәмче системаларның көчләр, чаралар составы һәм эше турында | ТП РСЧС шәһәр звеносы составына керә торган оешмалар | 1. Яр Чаллы шәһәренең гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комиссиясенә.<br>2. Яр Чаллы шәһәре БДДХга | узган ел өчен - ел саен 1 гыйнварга |

Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә мәгълүмат җыю, аны алмашу һәм Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан хакимият органнарына һәм оешмаларга хәбәр итү тәртибенә 3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнары һәм оешмалар, Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнары арасында алмашу барышында (Яр Чаллы шәһәренең БДДХ аша) тапшырыла торган мәгълүмат исемлеге

| № т/б | Мәгълүматның эчтәлеге | Тапшыру срогы | Тапшыру форматы | Ешлыгы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарына һәм оешмаларына, Яр Чаллы шәһәренең җирле үзидарә органнарына Яр Чаллы шәһәренең БДДХдан | | | | |
| 1. | Булуы ихтимал гадәттән тыш хәлләргә тәүлек саен оператив фараз | запрос буенча | текстлы документ | тәүлек саен |
| 2. | Гадәттән тыш хәлләр һәм һәлакәтләр янау турында | кичекмәстән | телефон аша | сәгать саен |
| 3. | Гадәттән тыш хәл һәм һәлакәт факты турында | кичекмәстән | телефон һәм факс аша | |
| 4. | Гадәттән тыш хәлләрнең һәм һәлакәтләрнең параметрлары | запрос буенча | телефон аша | һәр 2 сәгать саен |
| 5. | Яр Чаллы шәһәре территориясендә булуы ихтимал гадәттән тыш хәлләр һәм һәлакәтләр турында оператив рәвештә кисәтү | кичекмәстән | текстлы документ | куркыныч янаганда |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан дәүләт хакимияте органнарыннан һәм оешмалардан | | | | |
| 1. | Булуы ихтимал гадәттән тыш хәлләргә тәүлек саен оператив фараз | запрос буенча | текстлы документ | тәүлек саен |
| 2. | Гадәттән тыш хәлләр һәм һәлакәтләр куркынычы турында, гадәттән тыш хәлнең (һәлакәтнең) халыкның тормыш эшчәнлегенә, социаль әһәмияткә ия һәм потенциаль куркыныч объектлар эшенә йогынтысы турында фаразлана торган мәгълүматлар, гадәттән тыш хәлнең (һәлакәтнең) исәп-хисап характеристикалары (исәп-хисап вакыты, тизлеге, таралу мәйданы, масштабларның артуы, хәлнең алга таба үсешенең исәп-хисап күрсәткечләре, зыян күргән халыкның, торак пунктларның, социаль әһәмияткә ия һәм потенциаль куркыныч объектларның исәп-хисап күрсәткечләре, зыянның исәп-хисап мәгълүматлары) | кичекмәстән | телефон аша | сәгать саен |
| 3. | Гадәттән тыш хәл яки һәлакәт барлыкка килү факты турында | кичекмәстән | телефон аша, 10 минуттан соң - текстлы документ | факт буенча |
| 4. | Гадәттән тыш хәлләрнең һәм һәлакәтләрнең параметрлары, аларның исәп-хисап характеристикалары | кичекмәстән | телефон аша, 10 минуттан соң - текстлы документ | һәр 2 сәгать саен |
| 5. | Объектның характеристикасы, гадәттән тыш хәлләрнең (һәлакәтләрнең) сәбәпләре, зыян күргән кешеләр саны, оешмалар (саны, исеме), гадәттән тыш хәлне бетерү өчен җәлеп ителгән көчләр һәм чаралар саны (фамилиясе, исеме, атасының исеме, өлкән вазыйфаи затның вазыйфасы, телефоны, төрләр буенча техника составы (үзара эшчәнлекне оештыру өчен чакыру, ешлыгы) | гадәттән тыш хәл яки һәлакәт барлыкка килгәннән соң 10 минут үткәч | текстлы документ | корректировка вакытында - кичекмәстән |
| 6. | Гадәттән тыш хәлләр һәм һәлакәтләр нәтиҗәсендә зыян күрүчеләр (хастаханәгә озатылучылар) исемлекләре | гадәттән тыш хәл яки һәлакәт турында | текстлы документ | сәгать саен |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | мәгълүмат кергән вакыттан башлап 1,5 сәгать эчендә | | |
| 7. | Гадәттән тыш хәл районына (зонасына) эләккән медицина учреждениеләре, социаль әһәмияткә ия, потенциаль куркыныч объектлар саны, электр энергиясе өзелү (исеме, адресы, телефон, кешеләр (авырулар) саны, резерв энергия чыганагы булу, җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, телефон номеры) | | текстлы документ | сәгать саен, корректировка вакытында - кичекмәстән |
| 8. | Гадәттән тыш хәл яки һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү буенча чаралар планы | гадәттән тыш хәл яки һәлакәт турында мәгълүмат кергән вакыттан башлап 1 сәгать эчендә | текстлы документ | |
| 9. | Гадәттән тыш хәл нәтиҗәләре, халыкның тормыш эшчәнлегенә, социаль әһәмияткә ия һәм потенциаль куркыныч объектларның эшенә (сүндерелгән светофорлар, сүндерелгән лифтлар һәм аларда бикләнеп калган кешеләр саны, юлларның, урамнарның, җир асты юлларының яктырткычларын сүндерү), аларны бетерүгә җәлеп ителгән көчләр һәм чаралар (көчләрнең һәм чараларның исемнәре, составы, кемгә каравы, фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм өлкән вазыйфаи затның вазыйфасы, аның элемтә телефоннары, урнашу урыны), гадәттән тыш хәлнең исәп-хисап күрсәткечләре, халыкның тормыш эшчәнлегенә, социаль әһәмияткә ия һәм потенциаль куркыныч объектлар эшенә йогынты ясый торган һәлакәтләр | гадәттән тыш хәл яки һәлакәт турында мәгълүмат кергән вакыттан башлап 1 сәгать эчендә | текстлы документ | сәгать саен, корректировка вакытында - кичекмәстән |